СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ТИМЯШЕВСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ТИМӘШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

2025 елның 29 апреле

№ 13

Лениногорск муниципаль районына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча авыл җирлеге вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2025 елның 23 апрелендәге 1-31/6492 номерлы авыл һәм шәһәр җирлекләре вәкаләтләрен тапшыру турындагы хатын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән Тимәш авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Лениногорск муниципаль районының вәкиллекле органына исәпкә алу буенча вәкаләтләр кабул итү, шулай ук муниципаль мөлкәт һәм авыл җирлегенең җир ресурслары белән эш итү турындагы тәкъдимне карауны тәкъдим итәргә.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советына карауга җибәрергә.

3.Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: ТР, Лениногорск районы, Тимәш авылы, Утыз Имәни ур., 71д йорт-җирле үзидарә бинасы, Киров ур., 26 йорт – җирле мәдәният йорты бинасы, нефть үткәрүчеләр ур., 20 йорт - Ромашкино РНУ БПО утырышлар залы, Киров ур., 1а йорт – «Ласточка» балалар бакчасы бинасы, Урман ур., 20 йорт, Урман ур., Урман ур., 33, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru)бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Тимәш авыл җирлеге муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе

Х.Х.Сөләйманова